ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге

422743, ТР, Әтнә муниципаль районы,
Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы,
17а йорт

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Атнинский муниципальный район
Нижнеберескинское сельское
поселение
422743, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Нижняя Береске, улица Совета,
дом 17а

Тел./факс: 8(84369)33403, E-mail: NBrs.Atn@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

КАРАР

13 ноябрь 2024 ел №4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законының 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы нигезендә **карар чыгарам:**

1. 2024 елның 23 ноябренә 19.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Түбән Бәрәскә авылы Чишмәле урамы 1 нче йорттан 75 нче йортка кадәр, Новая урамы 4 нче йорттан 56 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2024 елның 25 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Түбән Бәрәскә авылы Совет урамы 1 нче йорттан 62 нче йортка кадәр, Культурная урамы 1 нче йорттан 14 нче йортка кадәр, Мира урамы 1 нче йорттан 37 нче йортка кадәр, Зеленая урамы 1 нче йорттан 16 нчы йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2024 елның 25 ноябренә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Түбән Бәрәскә авылы Казаклар урамы 1 нче йорттан 15 нче йортка кадәр, Татарстан урамы 1 нче йорттан 16 нчы йортка кадәр, Ленин урамы 3 нче йорттан 62 нче йортка кадәр, Центральная урамы 1 нче йорттан 17 нче йортка кадәр, Тукай урамы 1 нче йорттан 13 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. Билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты;
- халык җыенының беренче этабын үткәрү вакыты - 23 ноябрь 2024 ел 19.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү вакыты - 25 ноябрь 2024 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- халык җыенының өченче этабын үткәрү вакыты - 25 ноябрь 2024 ел 14.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр;
- халык җыенының беренче этабын үткәрү урыны - Түбән Бәрәскә авылы, Чишмәле урамы, 21 нче йорт, күпфункцияле үзәктә;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны - Түбән Бәрәскә авылы, Чишмәле урамы, 2 нче А йорт, фельшер-акушерлык пункты янында;
- халык җыенының өченче этабын үткәрү урыны - Түбән Бәрәскә авылы, Казаклар урамы, 8 нче йорт, ветеринар пункт янында.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 18 нче ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Бәрәскә авылы, Совет урамы, 17 нче а йорты;
- сайлау хокукына ия булган Түбән Бәрәскә торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Түбән Бәрәскә торак пункты халкына гражданнар җыены турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Түбән Бәрәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Бәрәскә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)); парк территориясен тчистарту (үлән чабу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2. Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

3. Традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Түбән Бәрәскә авылында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлау, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау (Түбән Бәрәскә авылы Зеленая урамындагы күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталыда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Бәрәскә авылы Совет урамы 17 нче а йорт адресы буенча Түбән Бәрәскә авыл башкарма комитеты стендына урнаштырырга.

8. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: А.В.Фатыхова